ГЛАВА
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

Ул. Красавина, д.40, с. Набережные Моркваши, 422594

Красавин ур., 40 нче йорт, Яр Буе Моркваши авылы, 422594

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                        КАРАР

11.11.2024                                                4

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

с. Набережные Моркваши

Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Моркваşы авыл җирлеге
Никольский поселогында акча кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Моркваşы авыл җирлеге Уставының 24 статьясына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 30 ноябренә Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Моркваşы авыл җирлеге Никольский поселогында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Моркваşы авыл җирлеге Никольский поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә сез риза булырсызмы:

- торак пункт территориясен төзекләндерү

«ӘЙЕ»                                                «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча: Никольский поселогы, Үзәк урам, 21а номерлы йорт янында 10.00 сәгатьтә уздырырга.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Яр буе Моркваşы авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Моркваşы авыл җирлеге башлыгы                                И. Х. Гаязов